РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА КИЧКАЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423038, с. Кичкальня, ул. Школьная, д.11
Тел./факс: 8-(84345) 4-42-30
Email: Kichk.Nur@tatar.ru,
ОКПО 27922845, ОГРН 1021605352460,0 ОКАТО 92246842000
ИНН/КПП 1632001554/163201001,
ОКТМО 92646442

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЧЫТКАНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423038, Кычытканлы авылы, Мәктәп ур, 11 йорт
Тел./факс: 8-(84345) 4-42-30
Email: Kichk.Nur@tatar.ru
ОКПО 27922845, ОГРН 1021605352460,0 ОКАТО 92246842000
ИНН/КПП 1632001554/163201001,
ОКТМО 92646442

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Кычытканлы ав. **КАРАР**

«08» ноябрь 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Кычытканлы авылы Мәктәп урамы 8нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында яшәүче гражданар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә халык җыенын үткәрү һәм оештыру эшләре белән Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы һәм Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Башкарма комитеты тәэмин итә.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә Заречная урамын төзекләндерү һәм карап тоту;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында торак пунктта су башнясы сатып алу һәм урнаштыру;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә суүткәргеч торбаларның аерым участокларын алыштыру һәм суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Сабиров